**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**КАРАР**

**05.11.2020ел**

**КАРАР**

**№2**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларының турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Иске Имән авылы клуб бинасында 2020 елның 18 ноябренә 09.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Иске Имән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2021 елда үзара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1.Иске Имән торак пунктнының авыл эчендәге Мулланур Вахитов, Нәҗип Вахитов урамы юлларын ремонтлау (вак таш түшәмәле чокырлар ремонтлау, сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

2.Иске Имән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

3. Иске Имән торак пунктының Каратал урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру ( килешү буенча эшләр өчен түләү);
4) Иске Имән торак пункты юлларын грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
5) Иске Имән торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
6) Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);
7) Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;
8) Иске Имән торак пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу.

"ӘЙЕ" “ЮК”.

4. Әлеге карарны Иске Имән авылы җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән 7 көн эчендә урнаштырыга.
5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге башлыгы: Р.Ә.Исламова